2011 елга Кырынды авыл жирлеге отчеты.

2010 елнын 14 октябрь аенда булган сайлауларда Кырынды авыл жирлеге советына 7 депутат сайланган иде. Шуларнын җидеседә эшли.

Советнын эше жирле үзидәрәгә кагылышлы законнарны камилләштерү, үзгәрешләр чорында алып барыла.

Ел дәвамында авылларда 11 тапкыр авыл җыеннары 8 көн тәртибе, 11 совет утырышы 23 көн тәртибе белән уздырылды. Аларда авылларны төзекләндерү, авыл җирлегенең бюджеты, учреждениеләрнең эшен оештыру, тирә-як мөһитне саклау, пожар куркынычсызлыгы чаралары, халыкны су белән тәэмин итү, җирле салымнарны җыю, бәйәрмнәре уздыру һәм башка мәсьәләләр каралды.

Ел дәвамында 1360 кеше авыл җирлегендә мөрәҗәгать иткән, 480 справка бирелгән.

2012 елның беренче гыйнварына 393 хуҗалыкта 791 кеше пропискада тора, шуларның 754е даими яши.

| | хуҗалык | кеше саны |
|---|---|---|
| | | |
| Кырынды | 303 | 645 |
| Чишмә | 38 | 58 |
| Тукай | 38 | 70 |
| Еленовский | 14 | 18 |
| Барлыгы | 393 | 791 |
| Пенсионерлар | 236 | |

2011 елда Кырынды авыл җирлегендә .

| | үлгән | туган | никах |
|---|---|---|---|
| Кырынды | 11 | 8 | 2 |
| | | | |
| Чишмә | - | - | - |
| | | | |
| Тукай | - | 1 | - |
| | | | |
| Еленовск | 3 | - | - |
| Барлыгы | 14 | 9 | 2 |

2012 елда гыйнвар-февральнең яртысына 3кеше үлде.
2012 елның беренче гыйнваренә халыкта

| | КРС | сыер | сарык-кәҗә | умарта | кош-корт |
|---|---|---|---|---|---|
| Кырынды | 213 | 100 | 39 | 57 | 682 |
| Чишмә | 15 | 6 | 8 | 5 | 101 |
| Тукай | 11 | 8 | 11 | 5 | 92 |
| Еленовск | 3 | 3 | 2 | - | 6 |
| Барлыгы | 242 | 117 | 60 | 67 | 1777 |

Маллар буенча арту кузәтелә. 2010 елга Караганда 33 башка артык.

Бабаларыбыз әйткән: «Малсыз кеше- җансыз кеше ,»-дип. Авыл җирендә яшәү чыганагының берсе булып терлекчелек тора. Шуңа күрәдә, соңгы елларда авыл халкына ярдәм итү максатыннан, дәүләт тарафыннан халыкка күп ярдәм ителә. 48 хуҗалык льготалы кредит алды. Шул исәптән, 2011 елда 11 кеше 2 млн 260 мең акча алды. үз эшеңне башлап җибәрү өчен (самозанятость) 58 мең сум субсидия 23 хуҗалык алды. 2012 елда ай ярым эчендә 550 мең сум алынган . 2012 елдан республикада яңа башлаучы фермерларга ярдәм программасы 2012-2014 елга кадәр эшли башлый. Программада 19 яшьтән 58 яшькә кадәр, җирлектә даими яшәүче, Республикада фермер хуҗалыгы теркәлгән, бер ел стажы булган кешеләр катнаша ала. Програмада катнашучыларга, фермер хужалыгын киңәйтү гә, тормыш шартларын ныгытуга, бизнез-план нигезендә, кире кайтарып бирелми торган субсидия биреләчәк. Беренче көндә шәхси хужалыкларда 17 ләп трактор, 127 җиңел машина, 19 йөк машинасы бар. Кырынды авыл җирлеге карамагында 449 га җир исәпләнә. Шуның 281 га көтүлек, табигый печәнлек.

2011 елда бюджет утәлеше белән таныштырып китәсем килә,

Керем барлыгы:

| | план | факт | % |
|---|---|---|---|
| Милек налогы | 6000 | 43000 | 716 |
| җир налогы | 43000 | 89600 | 208 |
| Подоходный налог | 106000 | 131700 | 124 |
| Госпошлина | 12000 | 11600 | 97 |
| Неналоговые доходы | 37000 | 18800 | 51 |
| Барлыгы җирлек милеге | 204000 | 294700 | 144 |
| Дотация | 2674200 | 2579800 | 97 |
| Военкомат | 59000 | 59000 | 100 |
| ЗАГС | 15000 | 15000 | 100 |
| Барлыгы керем | 2952200 | 2948500 | 99 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Расход барлыгы | 2952200 | 2910500 | 99 |
| Совет | 250000 | 267800 | 107 |
| Исполком | 323000 | 332400 | 103 |
| Бухгалтерия | 242000 | 148600 | 61 |
| СДК | 728700 | 717500 | 98 |
| Военкомат | 59000 | 59000 | 100 |
| ЖКХ | 112000 | 105000 | 94 |
| ЗАГС | 15000 | 15000 | 100 |

В небюджет счетына 133 мең 100 сум акча керде. Түләүле хезмәт, клубларга план 5000 сум булса, фактический 5000 сум 100%.

Самообложение- узара салым-100 сум калдырырга. Шул сумманы калдырырга кем риза, кул күтәреп ризалыгын сорыйм. План буенча 12000сум-җыелган , 9000 сум-калган, 3000 сум җыелган.

Халыктан су белән тәэмин итү проблемаларыбыз бик күп. Бу өлкәдә 15 тапкыр ремонт эшләрен испкә алмаганда, өзеклекләр булмады. Су белән тәэмин итү халыктан тариф буенча су өчен җыелган акча исәбенә оештырыла. Барлыгы 2011 елда 126600 сум җыелган. Шул исәптән банкка 119100 сум тапшырылган. Бу суммадан 96507 электроэнергиягә

кучерелде, 22593 налогларга ките. 7500 тракторчыга эш хакы түләдек.

Суга лицензия алырга кирәк. Лицензия авыл җирлекләренә бирелми, шуның өчен ИП ачарга, документация, паспортизация, скважиналарга гидрологическое заключение, җиһазлар алырга кирәк.

Пожардан саклану чаралары.

Бу эшкә әлегә дәүләттән акча каралмаган. Шуңа күрә халык җыелышы карары белән һәр хуҗалыктан 100 сум акча җыябыз. 2011 елда халыктан 9850 сум акча җыелды. Бер кеше билгеләнеп куелган ( Батыров Ильгиз). җыелган суммадан эш хакы 500 сум, зап.частьлар 15000 сум, утеплитель трубаларга 224 сум тотылды. Барлык расход 15724 сум.

2012 елда 76683 квт электр энергиясе тотылган.

Шул исәптән

| | квт | сум |
|---|---|---|
| Урам яктыртырга | 37611 | 122169,93 |
| ВНБ | 28408 | 92276,29 |
| СДК | 4750 | 15429,19 |
| Котельный | 5914 | 19210,15 |
| Барлыгы | 76683 | 249085,56 |

Ак-Барс көче белән урамнарны кардан чистартып торабыз.

Учреждениеләрнең эше.

Кырынды башлангыч мәктәбендә быелгы уку елында 20 бала белеем ала. Ике класс комплект. Шуларның 8 рус милләтеннән, 12 се татар, 7 бала опекун гайләдән. 3 бала өйдә белем ала. һәр бала бушлай китап белән тәэмин ителгән. Бу уку елында ата-аналар тарафыннан китап дәреслекләр сатып алынмады. Мәктәптә 3 тугәрәк эшли, бию түгәрәге, шахмат, оста куллар,экологик тәрбия юнәлешендәге түгәрәкләр. 100 % укучы жылы аш белән тәэмин ителгән. һәр укучы көненә 5 сум 20 тиенлек бушка ашатыла. Бакчадан алынган яшелчәләр

шулай ук түләүсез. Укучыларның туклану сыйфатыннан ата-аналар да, укучылар да каннәгәт.

«Сөмбелә» балалар бакчасында 24 бала тәрбияләнә. 2 бала-6 яшьлек, 6 бала – 5 яшьлекләр, 6 бала – 4 яшьлекләр, 5 бала - 3 яшьлекләр, 5 бала – 2 яшьтән алып, 8 сотрудник эшли. Шартлар начар түгел. Ремонт эшләре башкарылды: Стена, идәннәр, тәрәзә, ишекләр буялды.

Авылда балалар күбәйде, опекун балалар күп, 6 заявление бар бакчага бирә өчен. Быелгыдан 2 группа ачылды.

Кырынды фельдшер- акушерлык пункты 7936 авыруга амбулатор ярдәм күрсәтелде, 6997 кешегә дәвалау үткәрелде, шул исәптән 1676 балага, 1744 кешегә өйләрендә ярдәм күрсәтелде, шул исәптән 536 сы күзәтү астында торды. 296 кеше табибка консультациягә ибәрелде. Прививкалар буенча 2011 елга бирелгән планны үтәде. Медицина пункты 633 кешегә хезмәт күрсәтү.

Җирлектә 3 райпо, 4 шәхси магазин эшли. Райпо магазиннары буенча товарооборот.

| | план | факт | үтлгән | зарплата |
|---|---|---|---|---|
| Кырынды | 4280500 | 4423800 | 103,3% | 6800 |
| Тукай | 1034300 | 839400 | 81% | 5580 |
| Чишм* | 649800 | 667000 | 102,6% | 4331 |

2011 елда җирлектә каты җинаять эшләре булмады. Участок инспеторы тарафыннан 3 җинаять эше кузгалтылган. Читтән килеп законсыз балык тотучыларга, 98 административ протокол төзелгән. 2 җинаять ачылган. Законнарда үзгәрешләр благоустройствоны бозган өчен кисәтү юк.

Халыкка, Кырынды мәдәният йорты хезмәт күрсәтелә. Һәр бәйрәмгә план нигезендә концерт, кичәләр уздырыла. Зур әзерлек белән яңа ел бәйрәмен, 9 Май - җиңү бәйрәмен уздырылды. Сугыш һәм тыл ветераннарына бүләкләр бирелде, чәй өстәле әзерләнде. Сабан-туй урынын әзерләү һәм бәйрәмне уздыру зур хезмәт сорый. СДК да 7 түгәрәк эшли.

Өлкәннәр көнендә бүләкләр өләшенде. Инвалидлар көне уздырылды.

Җирлектә бер социаль хезмәкәр 5 ялгыз өлкән кешегә хезмәт күрсәтә.

Китапханәгә 501укучы йөри. Балалар өчен “Бәллүр каләм “ түгәрәге эшләп килә. Өлкәннәр өчен “Ильһам” түгәрәге эшли.

Авыл жирлегендә 236 песионерыбыз бар Ай саен пенсионерларыбызга 180000 сум субцидия бирелә.

“ Мәктәпкә барырга булыш” акциясендә катнашып 3 балага ярдәм күрсәтелде.

2012 елга Кырынды авыл жирлеге бюджеты.

| Доход | План годовой |
|---|---|
| Налог на имущество | 80000 |
| Земельный налог | 155000 |
| Налог на доходы с физ. Лиц | 110000 |
| Единый сельхозналог | 2000 |
| Неналоговые доходы | 19000 |
| Госпошлина | 3000 |
| Итого собственных доходов | 369000 |
| Дотация из районного фонда сбалан-Сированности бюджетов поселений | 1600 |
| ЗАГС | 15000 |
| Военкомат | 57000 |
| Всего доходов | 2343900 |
| РАСХОДЫ | |
| Культура | 999500 |
| ЖКХ | 160400 |
| Аппарат | 573000 |
| Централизованная бухгалтерия пла-тежи за негативное воздействие на окружающую среду налог на иму-щество организации | 433800 |
| ЗАГС | 15000 |
| Военкомат | 57000 |
| Итого расходов | 2343900 |

Авылда яшәү өчен шартлар бар: электроэнергия, газ, су, телефон, интернет. Кайсы гына якка чыгып китсә дә юлыбыз бар. әлбәттә, авыл урамнарын карыйсы бар,- алга таба анысы да булыр, дип ышанасы килә. Эш проблемалары бар барын. Ничек кенә зарлансак та, дөнья алга таба бара, яхшыга таба. бәлки эш юк, дип ятмаскадыр, үзебезгә кыюрак булырга, эштән курыкмаска кирәктер, үз- үзебезгә эш урыны булдырырга, үз эшебезне ачарга.

Соңгы елларда моның өчен күп шартлар тудырылды. Эш башларга акчаң булмаса, льготалы кредит ал: ЛПХ.

Самозанятостька 58000 сум. Законда рөхсәт ителгән төрле эшне ач! Бала тудырсаң, икенче балага 387000 сум материнский капитал, өченче балаң булса, 18 яшькә кадәр, йорт салырга бушлай җир участогы бирелә. Сыерларны саклап калу өчен корылык килгәндә берничә тапкыр терлек азыгы алырга акча бирелде. Гайлә фермасы ачсаң 1 млн 700 мең сум кире кайтарусыз акча ал “сыерга”. Куян, сарык, балык, корт асра, яшелчә үстер.

Бер сугыш ветераны, сигез сугыш ветеранының хатыннары квартира алды, тагын алачаклар.

Президент тарафыннан “ Чиста су” программасы яңадан күтәрелә.

Нәрсә генә әйтсәк тә, соңгы елларда дөнья тотрыклы рәвештә алга таба бара. Әйтеп үтелгәннәр барысы да халыкка ярдәм түгелме! Дәүләт ярдәменнән файдаланып, курыкмыйча алга атларга. Барыгызга да сәламәтлек, байлык, муллык, тыныч тормыш, иминлек телим. 4 мартта барыгызда да сайлауларга рәхим итегез.